СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)93-1-24, факс (84366)93-1-24. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

# КАРАРЫ

**30 октябрь 2023 ел** **№ 5**

**Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Чөмә-Елга авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Чөмә-Елга авылында Чөмә- Елга авылы, З.Гомәрова урамы, 43А йорт каршында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 16 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Чөмә-Елга авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урам утлары челтәрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр (кирәк булганда) сатып алу һәм урнаштыру;

-вак таш сатып алу һәм китерү,З. Гумарова урамындагы җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешен вак таш белән өлешчә тигезләү ;

- бензин генераторын сатып алуны финанслашу;

- МТЗ 82.1 тракторының асылмалы җиһазы чапкыч өчен пычаклар комплекты сатып алуны финанслашу ;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Чөмә-Елга авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Чөмә-Елга авылы, З.Гомәрова урам, 43А, нче йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хәмидуллин